СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

11.01.2016 пос. Октябрьский 5-33

Октябрьский авыл җирлеге территориясендә үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Октябрьский авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2015 елның 16 декабрендәге 4-27 номерлы Октябрьский авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2015 елның 16 декабрендәге 7 номерлы Октябрьский авыл җирлеге башлыгы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2016 елның 06 мартына Октябрьский авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия авыл җирлегенең һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юлламасы белән риза булырсызмы:

- Октябрьский авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге торак пунктлары юлларын 850 метр озынлыктагы вак таш җәелгән юл белән 170000 сумлык төзекләндерү.

ӘЙЕ ЮК".

3. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында бастырып чыгарырга, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов